ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СРЕДНЕКОРСИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Молодежная, д.13, д. Средняя Корса,
Арский муниципальный район, 422024

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРТА КУРСА
АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Яшьләр ур, 13 нче йорт, Урта Курса авылы,
Арча муниципаль районы, 422024

Тел. (84366) 53-4-32, факс (84366) 53-4-32. E-mail: Skor.Ars@tatar.ru

**КАРАР**

« 18 » декабря 2020 ел № 27

**«Урта Курса авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гражданнардан үзара салым акчалары җыю Тәртибе турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы « Урта Курса авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы составына керә торган торак пунктларда халык җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында» Урта Курса авыл җирлеге советының 31.10.2019 ел, №101 карары, 10.11.2020 ел, №1, 10.11.2020 ел, №2, 11.11.2020 ел, №3, 11.11.2020 ел, №4, 12.11.2020 ел, №5, 13.11.2020 ел, №6 җыеннарда кабул ителгән карарларны гамәлгә ашыру максатыннан, Урта Курса авыл җирлеге Башкарма комитеты карар бирә:

1.« Урта Курса авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гражданнардан үзара салым акчалары җыю Тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районы рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru) һәм ТР, Арча районы, Урта Курса авылы, Тукай урамы, 21 йорт, ТР, Арча районы, Корайван авылы, М. Гафури урамы, 9 йорт, ТР, Арча районы, Сарай-Чокырча авылы, Зур Кызыл урамы, 21 йорт, ТР, Арча районы, Алан авылы, Х. Такташ урамы, 23 йорт каршында, ТР, Арча районы, Түбән Курса авылы, Мәскәү урамы, 30а йорт, ТР, Арча районы, Югары Курса авылы, Мәктәп урамы, 16а йорт адреслары буенча гражданнар күпләп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Урта Курса авыл җирлеге Башкарма комитетының 31.12.2019ел, №63 «Урта Курса авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гражданнардан үзара салым акчаларын җыю Тәртибе турында" карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Урта Курса авыл җирлеге башлыгы Р.Р. Вафина

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ СРЕДНЕКОРСИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

Урта Курса авыл җирлеге
башкарма комитетының
18.12.2020 ел, № 27 карарына
1 нче кушымта

**«Урта Курса авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гражданнардан үзара салым акчалары җыю Тәртибе**

1. Әлеге Тәртип «Урта Курса авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гражданнардан үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Гражданнарның үзара салым акчаларын түләү, җыеннарда катнашуларына һәм тавыш биргәндә күрсәткән мөнәсәбәтләренә бәйсез рәвештә, 2021 елның 21 февраленә кадәр муниципаль берәмлек территориясендә теркәлгән 18 яшькә җиткән гражданнар тарафыннан башкарыла.

3. Аерым категория гражданнар өчен:

а)көндезге уку формасы буенча укучы студентлар,

б) тумыштан булган инвалидлар,

в) 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнар өчен

түләү күләме җирле җыеннар карарында билгеләнгән сумманың 50 (илле) процентын тәшкил итә.

г) Россия армиясендә вакытлы хәрби хезмәт узучы затлар өчен түләү күләме 100 сум тәшкил итә

4. Нигезле сәбәпләр булганда:

а) гаилә әгъзасының үлеме (ата-ана, хатыны/ире, балалары),

б) янгын яки башка табигый бәла-казалар нәтиҗәсенә зыян килү,

гражданнарга гариза нигезендә өч айдан да артмаган вакытка түләү кертүне кичектереп тору каралган булырга мөмкин.

5. Бер тапкыр түләнә торган түләү турында хәбәр (хәбәрнамә) бланкы гражданнар игътибарына (http://pravo.tatarstan.ru) сайтында басылып чыгу юлы белән хәбәр ителә һәм Арча муниципаль районы рәсми сайтында ( http://arsk.tatarstan.ru/) һәм гражданнар күпләп җыела торган урыннарда мәгълүмати стендларда, шулай ук кул куйдырып үзенә тапшыру яисә почта аша җибәрү юлы белән халыкка җиткерелә.

Хәбәрдә (хәбәрнамәдә) гражданнарга үзара салым акчаларын күчерү өчен түләү реквизитлары, тулы яки киметелгән күләмдә бер тапкыр түләү суммасы, аны түләү срогы булырга тиеш.

6. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акчалар «Урта Курса авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең шәхси счетына керә.

7. Гражданнар тарафыннан түләүләр физик затлар йөкләмәсе буенча исәп-хисап ясау хокукына ия булган оешмалар аша почта күчермәләрен (исәп-хисап оешмалары) гамәлгә ашыру юлы белән башкарыла, «Урта Курса авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең башкарма комитеты кассасы яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталы аша сылтама https://uslugi.tatarstan.ru/ буенча башкарыла.

8. Түләүне дәлилли торган документ булып керем касса ордеры, чек-ордер квитанциясе, түләү фактын раслаучы башка документлар тора.

9. Билгеләнгән вакытка кертелмәгән үзара салым акчалары законнарда билгеләнгән тәртиптә түләттерелә.

Урта Курса авыл җирлеге
башкарма комитетының
18.12.2020 ел, №27 карарына
2 нче кушымта

ХӘБӘР (ХӘБӘРНАМӘ) № _______________

«Урта Курса авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджетына үзара салым буенча бер мәртәбә түләнә торган түләү турында

Түләүченең ф. и. а.и.______________________________________________________
Адресы:_________________________________________________________________
____________________________________________________________нигезендә
Сезгә ___________ кадәр _________ сум күләмендә
____________________________________чаралар гамәлгә ашыру өчен
түбәндәге реквизитлар буенча:
БИК банк ___________________________
Сч. № ________________________________________
Счетны алучы. № _______________________________
ИНН ____________________________________________
КПП ____________________________________________
КБК __________________ОКАТО__________________
Түләү билгеләнеше
____________________________________________________________________бер
тапкыр түләү түләргә кирәк.

Җитәкче _________________ ________________________________________

М. у. (имза) ( имзаны аңлату)

- - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - кисү линиясе - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - -

«_________ авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджетына __ сум күләмендә бер мәртәбә түләнә торган үзара салым түләү буенча хәбәр (хәбәрнамә) № ___
Түләүченең ф. и. а.и.___________________________________________
Адресы: _______________________________________________
Алдым «___» ________________ 20__ ел ___________________________________
(имза/түләүченең ф.и.а.и.)

*Искәрмә: хәбәрнамә түләүчегә шәхсән бирелгән очракта, өзмә корешок тутырыла һәм ул _____________ авыл җирлеге башкарма комитетында кала.*